**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советы карары**

**2021 елның 18 июне** **№32**

**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советының 2018 елның 14 ноябрендәге 102 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына территорияләрне комплекслы үстерүне тәэмин итү максатларында үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 494-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 7 пункты нигезендә «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советы карар чыгарды:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советының 2018 елның 14 ноябрендәге 102 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турынданигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 2 өлешендәге 6 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

2) 12 статьяда:
өченче абзацта» сүзләрен өстәргә, әлеге статьяның дүртенче абзацында билгеләнгән очраклардан тыш.»;
түбәндәге эчтәлекле яңа дүртенче абзац өстәргә:
«Территорияне комплекслы үстерү турындагы карар кабул ителүгә бәйле рәвештә җирлекнең генераль планына үзгәрешләр әзерләнгән очракта, иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә үткәрелергә мөмкин.»;

дүртенче, бишенче һәм алтынчы абзацларны бишенче, алтынчы һәм җиденче абзацлар дип санарга.

3) 13 статьяны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Кама Тамагы ш.т.п., Совет ур., 11 йорт (административ бина)

- ТР, Кама Тамагы районы, Кама Тамагы ш.т.п., К. Маркс ур., 105 йорт (китапханә бинасы)

шулай ук Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга (https://kamskoye-ustye.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары Дәүләтшин Раил Хәмит улына йөкләргә.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы «Кама Тамагы
шәһәр тибындагы поселогы»
муниципаль берәмлеге Башлыгы - Совет рәисе Н. А.Вазыйхов